ГЛАВА СТАРОАЙМАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423739, село Старое Айманово,
ул.Новая, дом 5А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423739, Иске Айман авылы, Яна
ур..,5А йорт

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

№1

06.11.2020ел

**Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлегенең Иске Айман торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Айман авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 16 ноябренэ билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

*юлларны ремонтлау һәм карау( ком һәм щебенка түшәү, грейдерлау, кардан чистарту);

-авыл җирлеге чикләрендә халыкны су һәм электр белән тәэмин итүне оештыру:

*су үткәрү системасын ремонтлау, карау,су чыганакларын лицензияләү һәм ремонтлау;

- халык күплэп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күплэп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру.

-белдерулэр тактасы эшлэтеп, урнаштырып кую

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Айман авылы, Яна урам, 5А йорты .

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Иске Айман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы М.Р.Ахметханов

Совет СТАРОАЙМАНОВСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021605559876
ИНН 1604001538